СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

12.12.2019 Баулы шәһәре № 244

«Баулы районына 90 ел»
медале турында

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының 90 еллыгы уңаеннан Баулы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. “Баулы районына 90 ел”юбилей медален гамәлгә кую.

2. Расларга:

“Баулы районына 90 ел” юбилей медале турында нигезләмәне (1нче кушымта).

“Баулы районына 90 ел” юбилей медаленең тасвирламасын (2нче кушымта).

“Баулы районына 90 ел” юбилей медаленә таныклыкны тасвирлауны (3нче кушымта).

3. Әлеге карарны pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм bavly.tatar.ru адресы буенча Баулы муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башлыгы урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы,
район Советы Рәисе Р.Х. Гатиятуллин

Баулы
муниципаль районы Советының
2019 елның 12.12. кабул ителгән
244 номерлы карарына
1нче кушымта

“Баулы районына 90 ел” юбилей медале турында
НИГЕЗЛӘМӘ

1. «Баулы районына 90 ел» юбилей медале (алга таба – юбилей медале) Баулы муниципаль районының бүләге булып тора.

2. Юбилей медале, Баулы муниципаль районының социаль-икътисади үсешенә юнәлдерелгән хезмәт, иҗтимагый һәм башка эшчәнлектәге казанышлары өчен, Баулы муниципаль районының тиешле хезмәт коллективларында 5 елдан да ким булмаган хезмәт стажы булган оешма, предприятие, учреждение хезмәткәрләренә, шулай ук пенсиягә чыккан югарыда күрсәтелгән хезмәт коллективлары ветераннарына тапшырылырга мөмкин.

3. “Баулы районына 90 ел” юбилей медале белән бүләкләү түбәндәгеләр үтенечнамәләре нигезендә рәсмиләштерелә:

Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органнары;

иҗтимагый оешмалар җитәкчеләре;

предприятие һәм учреждение җитәкчеләре.

4. «Баулы районына 90 ел» юбилей медале белән бүләкләү турындагы үтенечнамә Баулы районы оешуга 90 ел тулуга багышланган чараларны оештыру һәм үткәрү буенча оештыру комитеты (алга таба - оештыру комитеты) утырышында карала.

Юлламаны карау нәтиҗәләре буенча оештыру комитеты карар кабул итә, ул Баулы муниципаль районы Башлыгының юбилей медале белән бүләкләү турындагы хокукый актын әзерләү өчен нигез булып тора.

5. “Баулы районына 90 ел” юбилей медален тапшыру Баулы муниципаль районы Башлыгы тарафыннан расланган юбилей медале белән бүләкләнүчеләр исемлекләре нигезендә башкарыла.

Юбилей медален тапшыру тантаналы шартларда Баулы муниципаль районы Башлыгы яисә аның кушуы буенча җирле үзидарә органнарының башка вазыйфаи затлары тарафыннан башкарыла.

Медаль белән бергә бүләкләнүчегә медаль таныклыгы тапшырыла.

6. “Баулы районына 90 ел” юбилей медален тапшыру аның иясенә социаль һәм башка ташламалар һәм гарантияләр бирү өчен нигез булып тормый.

7. “Баулы районына 90 ел” юбилей медале күкрәкнең сул ягында йөртелә. Дәүләт бүләкләре булган очракта, истәлек медале дәүләт бүләкләреннән түбәнрәк урнаштырыла.

8. «Баулы районына 90 ел» юбилей медале белән бүләкләү турындагы язма хезмәт кенәгәсенә Баулы муниципаль районы Башлыгының карарының датасын һәм номерын күрсәтеп кертелә.

9. «Баулы районына 90 ел» юбилей медале белән бүләкләнгән гражданнар реестрын Баулы муниципаль районы Советы Аппаратының оештыру бүлеге алып бара.

Баулы
муниципаль районы Советының
2019 елның 12.12. кабул ителгән
244 номерлы карарына
2нче кушымта

“Баулы районына 90 ел” юбилей медаленең
ТАСВИРЛАМАСЫ

«Баулы районына 90 ел» юбилей медале – латуньнан эшләнгән, 29 мм диаметрлы, ике яктан да чыгып торган әйләнеш формасындагы бортиклары бар.

Медальнең алгы ягында – “Баулы муниципаль районы” муниципаль берәмлеге гербы сурәтләнгән. Әйләнә буенча «Баулы районына 90 ел» дип язылган. Барлык сурәтләр, язулар һәм саннар рельефлы.

Медаль күркә һәм божра ярдәмендә яшел төсле эмаль белән капланган бишпочмаклы колодка белән тоташа. Колодканың зурлыгы – 21x18мм.




“Баулы районына 90 ел” медале рәсеме

Баулы
муниципаль районы Советының
2019 елның 12.12. кабул ителгән
244 номерлы карарына
Знче кушымта

“Баулы районына 90 ел” юбилей медаленә таныклыкны
ТАСВИРЛАУ

Таныклык 10,7х15,7см зурлыктагы китапчыктан гыйбарәт.

Таныклыкның алгы ягында түбәндәге язу бар: «Баулы районына 90 ел» юбилей медаленә таныклык.

Эчке якта «Баулы районына 90 ел» дигән язу, медаль сурәте, бүләкләнүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме, Баулы муниципаль районы Советының карары номеры һәм датасы, имза, мөһер, бирү датасы язылган.

<table>
<tr>
<td>«Баулы районына 90 ел»<br><br>
<br><br>№ 000</td>
<td>________________________________<br>(фамилия)<br>________________________________<br>(исем)<br>________________________________<br>(атасының исеме)<br><br>Баулы<br>муниципаль районы Советының<br>2019 елның «___»__________ кабул<br>ителгән<br>____ номерлы карары белән<br><br>«Баулы районына 90 ел» юбилей медале<br>белән бүләкләнгән<br><br>Баулы муниципаль<br>районы башлагы Р.Х. Гатиятуллин<br><br>МУ<br>«___»____________2019 ел</td>
</tr>
</table>

Юбилей медаленә таныклык рәсеме